| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
| 21.06.2019 | Казан ш. | № 5-3/тэ |

«Казэнерго» акционерлык җәмгыяте өчен җылылык энергиясен кулланмаганда резерв җылылык куәтен саклап тоту хезмәте күрсәтүгә түләү билгеләү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасына туры китереп, «Казэнерго» акционерлык җәмгыяте кулланучысы – Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казанның интенсив күзәтүле махсуслаштырылган типтагы психиатрия хастаханәсе (стационар)» федераль казна учреждениесе өчен җылылык энергиясе кулланмаганда резерв җылылык куәтен саклап тоту хезмәте өчен түләү билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән түләү карар үз көченә кергән көннән башлап 2019 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис в.б. А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 21.06.2019 № 5-3/тэ карарына кушымта

«Казэнерго» акционерлык җәмгыяте кулланучысы – Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казанның интенсив күзәтүле махсуслаштырылган типтагы психиатрия хастаханәсе (стационар)» федераль казна учреждениесе өчен җылылык энергиясе кулланмаганда резерв җылылык куәтен саклап тоту хезмәте өчен түләү*

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынучы оешманың аталышы | Ел | Резерв җылылык куәтен саклап тоту хезмәте өчен түләү, мең сум/Гкал/ аена сәг. |
|---|---|---|---|
| | Казан шәһәре | | |
| 1 | «Казэнерго» акционерлык җәмгыяте | карар үз көченә кергән көннән башлап 31.12.2019 кадәр | 86,447 |

<*> Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары белән расланган Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү нигезләренең 115 пункты нигезендә, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казанның интенсив күзәтүле махсуслаштырылган типтагы психиатрия хастаханәсе (стационар)» федераль казна учреждениесе белдерелгән резерв куәте 0,67 Гкал/сәг тәшкил итүче социаль әһәмиятле кулланучыга карый.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге